**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ МОЛЬКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ МӘЛКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**30.01.2020 ел** **Мәлки ав.** **№ 3**

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл жирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә курсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында**

2003 елның 06 октябрендәге 131-03 номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон, 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы «Җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 нчы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 29 гыйнварындагы 61 номерлы «2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында» карары нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Мәлки авыл жирлеге» муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымталарга туры китереп 6124,86 сум күләмендә билгеләргә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:// molkeev-kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Ф.П.Поляков

Мәлки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 ел «30» гыйнвар
3 номерлы карарына
1нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү атамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум)*** |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2627,72 |
| 3. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәде калдыкларын) зиратка күчерү | 703,47 |
| 4. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2793,67 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |

Мәлки авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2020 ел«30» гыйнвар
3 номерлы карарына
2 нче кушымта

**«Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының Мәлки авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| **Хезмәт күрсәтү этамасы** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (сум)** |
|---|---|
| 1. Күмү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0 |
| 2. Кәфенләү | 330,34 |
| 3. Мәет җирләү өчен кирәкле табут һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 2297,38 |
| 4. Мәрхүмнең җәсәден (җәсәде калдыкларын) зиратка күчерү | 703,47 |
| 5. Күмү (кабер казу һәм күмү) | 2793,67 |
| **Барлыгы** | **6124,86** |